**Республика Татарстан**
**Глава Абалачевского сельского поселения Менделеевского муниципального района**
ул. Центральная д. 35, помещ.1, д. Абалачи
Менделеевский район, 423657

**Татарстан Республикасы**
**Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Башлыгы**
Үзәк урамы, 35, бина 1, Абалач авылы,
Менделеевск районы, 423657

тел./факс (85549)3-65-49 Email: Abal.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 ноябрь 2025 ел № 3

“2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы "Абалач авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге бюджеты турында"
карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру хакында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге советы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 5 декабрендә “2026 елга һәм 2027-2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы " Абалач авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге бюджеты турында" Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советы карар проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Гавами тыңлаулар уздыру урыны итеп Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Абалач авылы, Үзәк урам, 35 йорт адресы буенча Абалач авыл мәдәният йорты бинасын билгеләргә. Үткәрү вакыты: 17 сәг.00 минут

3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: Татарстан Республикасы, Менделеевск муниципаль районы, Абалач авылы, Үзәк урам, 35 йорт, Абалач авыл җирлеге Башкарма комитеты яисә электрон почтага: Abal.Men@tatar.ru u (эш көннәрендә 8:00 - 16:00 кадәр).

4. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты - 2025 елның 5 декабренә кадәр.

5. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән

билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Н. Әкбәров